**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3756**
**13.06.2024**

Башкарма комитетның 2023 елның 2 октябрендәге 9357 номерлы Карары белән расланган «2024-2027 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлегенә ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, шәһәр Уставының 41 статьясы, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2023 елның 2 октябрендәге 9357 номерлы Карары белән расланган «2024-2027 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлегенә ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 бүлектә «Программаның бурычлары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Программаның бурычлары | 1. Кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү өчен инфраструктураны үстерү.<br>2. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, шул исәптән социаль эшмәкәрлеккә мәгълүмати-консультация ярдәме күрсәтү.<br>3. Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүдә административ каршылыкларны киметү.<br>4. Белем бирүдә ярдәм күрсәтү һәм эшмәкәрлек эшчәнлеген, шул исәптән социаль эшмәкәрлекне популярлаштыру.<br>5. Кооперация элемтәләрен үстерү.<br>6. Басма продукция сату буенча стационар булмаган сәүдә объектлары белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен күтәрү.»; |

2) 3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3 бүлек. Программаның төп максаты һәм бурычлары

Программаның максаты булып эшмәкәрлекнең тотрыклы үсешен тәэмин итү, КУЭ субъектлары җитештерә торган товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) өлешен Яр Чаллы шәһәре предприятиеләре тарафыннан җитештерелә торган продукция күләмендә арттыру өчен шартлар тудыру тора.

Әлеге максатны тормышка ашыру өчен түбәндәге өстенлекле бурычларны хәл итәргә кирәк:

- КУЭга ярдәм күрсәтү өчен инфраструктураны үстерү;
- КУЭга, шул исәптән социаль эшмәкәрлеккә мәгълүмати-консультация ярдәме күрсәтү;
- КУЭны үстерүдә административ каршылыкларны киметү;
- белем бирүдә ярдәм күрсәтү һәм эшмәкәрлек эшчәнлеген, шул исәптән социаль эшмәкәрлекне популярлаштыру;
- кооперация элемтәләрен үстерү;
- басма продукция сату буенча стационар булмаган сәүдә объектлары белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен күтәрү.»;

3) 4 бүлекне кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә;

4) 5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5 бүлек. Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары

| № т/б | Күрсәткечләрнең исеме | Исәпләү формуласы | Чыганак | 2023 факт | 2024 | 2025 | 2026 | 2027 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Тулаем территориаль продуктта (ТТП) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының өлеше), % | Исәп-хисапсыз | Татарстанстат | 30,3 | 30,4 | 30,5 | 30,6 | 30,6 |
| 2 | КУЭдан шәһәр бюджетына салым түләүләренең чагыштырма күләме, % | Исәп-хисапсыз | Яр Чаллы шәһәре буенча Федераль салым хезмәте идарәсе | 35,0 | 35,5 | 35,9 | 36,0 | 36,0 |
| 3 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә исәптә торучы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары саны, берәмлек | Исәп-хисапсыз | Татарстанстат, шәһәр паспорты | 26948 | 26950 | 26960 | 26970 | 26980 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4 | Кече һәм урта эшмәкәрлек өлкәсендә мәшгульләр саны, кеше | Исәп-хисапсыз | Татарстанстат, «КП һәм ШЭ тикшерүнең кайбер нәтиҗәләре» таблицасы | 98771 | 98800 | 98850 | 98900 | 98950 |
| 5. | Кече һәм урта предприятиеләрнең товар әйләнеше, млрд. сум | Исәп-хисапсыз | Татарстанстат, «КП һәм ШЭ тикшерүнең кайбер нәтиҗәләре» таблицасы | 506,4 | 529,6 | 556,1 | 585,1 | 615,5 |
| 6. | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен сатып алуларда катнашу өлеше, % | Исәп-хисапсыз | Башкарма комитетның муниципаль заказ бүлеге | 50,0 | 50,5 | 51,0 | 51,5 | 52,0 |
| 7. | Басма продукция сату буенча стационар булмаган сәүдә объектларының саны, берәмлек | Исәп-хисапсыз | Башкарма комитет икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсенең кулланучылар базары бүлеге | 3 | 5 | 6 | 7 | 8». |

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2024 елның 13 июнендәге
3756 номерлы карарына
кушымта

## 4 бүлек. Программа чараларының исемлеге

| № т/б | Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны башкару сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | | Финанслау чыганагын күрсәтеп финанслау, (мең сум) | | | | Көтелгән нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2023 факт | 2024 | 2025 | 2026 | 2027 | 2024 | 2025 | 2026 | 2027 | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
| 1 бурыч. Кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү инфраструктурасын үстерү | | | | | | | | | | | | | | |
| 1. | Сәнәгать (индустриаль) паркларын һәм сәнәгать мәйданчыкларын үстерү | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе | 2024-2027 еллар | Җәлеп ителгән резидентлар саны, берәмлек | 10 | 10 | 10 | 10 | 10 | - | - | - | - | Булдырылган эш урыннары санын арттыру, салым чигерүләрен арттыру |
| 2. | Күргәзмәләр үткәрүдә ярдәм күрсәтү | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе | 2024-2027 еллар | Ел саен күргәзмәләр саны, берәмлек | 3 | 3 | 3 | 3 | 3 | - | - | - | - | Шәһәрдә күргәзмә эшчәнлеген киңәйтү |
| 3. | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү өчен муниципаль мөлкәт исемлеген әзерләү | Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе | 2024-2027 еллар | Исемлектәге объектлар саны, берәмлек | 20 | 21 | 22 | 23 | 24 | - | - | - | - | Муниципаль мөлкәтне кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү буенча тәкъдимнәр булу |
| 2 бурыч. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, шул исәптән социаль эшмәкәрлеккә мәгълүмат-консультация ярдәме күрсәтү | | | | | | | | | | | | | | |
| 4. | Эшмәкәрлек субъектларына, шул | Башкарма комитетның | 2024-2027 еллар | КУЭның хәбәр | 1250 | 1260 | 1270 | 1280 | 1290 | - | - | - | - | Яңа производстволар ачу яки гамәлдәге |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | исәптән социаль эшмәкәрлеккә федераль һәм республика дәрәҗәсендә финанс ярдәме чаралары турында мәгълүмат бирү | икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе | | ителгән субъектлары саны, берәмлек | | | | | | | | | | производстволарны киңәйтү |
| 5. | Эшмәкәрлек субъектларына, шул исәптән социаль эшмәкәрлеккә шәһәрдә, башка шәһәрләрдә, илләрдә үткәрелә торган эшмәкәрлек эшчәнлеге белән бәйле чаралар (семинарлар, конкурслар, күргәзмәләр, мастер-класслар) турында мәгълүмат бирү | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе | 2024-2027 еллар | КУЭның хәбәр ителгән субъектлары саны, берәмлек | 1250 | 1260 | 1270 | 1280 | 1290 | - | - | - | - | Яңа производстволар ачу, эшмәкәрләрнең конкурсларда, күргәзмәләрдә катнашуы |
| 3 бурыч. Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүдә административ каршылыкларны киметү | | | | | | | | | | | | | | |
| 6. | Яр Чаллы шәһәре Хакиме карамагындагы Эшмәкәрлек советы утырышларын, шул исәптән күчмә утырышларны уздыру | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе | 2024-2027 еллар | Үткәрелгән утырышлар саны, берәмлек | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | - | - | - | - | Шәһәрдә инвестиция проектларын тормышка ашыру өчен муниципаль дәрәҗәдәге мәсьәләләрне хәл итү |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 7. | Эшмәкәрлек инфраструктурасын барлыкка китерә торган оешмалар белән утырышлар, очрашулар уздыру | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе | квартал саен 2024-2027 еллар | Үткәрелгән чаралар саны, берәмлек | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | - | - | - | - | Эшмәкәрлек өлкәсендә системалы мәсьәләләрне коллегиаль хәл итү |
| 4 бурыч. Белем бирүдә ярдәм күрсәтү һәм эшмәкәрлек эшчәнлеген, шул исәптән социаль эшмәкәрлекне популярлаштыру | | | | | | | | | | | | | | |
| 8. | «Ел эшмәкәре» шәһәр конкурсын үткәрү | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе | 2024-2027 еллар | Конкурста җинүчеләр саны, кеше | 10 | 10 | 10 | 10 | 10 | 50,2 | 50,2 | 50,2 | 50,2 | Уңышлы эшмкәрләрне ачыклау һәм бизнесменның уңай имиджын формалаштыру |
| 9. | «Автокаланың яшь эшмәкәре» конкурсын үткәрү | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | 2024-2027 еллар | Конкурста җинүчеләр саны, кеше | 5 | 5 | 5 | 5 | 5 | 112,8 | 112,8 | 112,8 | 112,8 | Уңышлы яшь эшмәкәрләрне ачыклау, яшьләр арасында нәтиҗәле тормыш стратегиясен формалаштыру |
| 10. | Көнкүреш хезмәте һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәткәрләре көне, тармакның иң яхшы хезмәткәрләрен хөрмәтләү | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе, Башкарма комитетның оештыру бүлеге | 2024-2027 еллар | Бүләкләнүчеләр саны, кеше | 20 | 20 | 20 | 20 | 20 | 38,0 | 38,0 | 38,0 | 38,0 | Эшмәкәрлек эшчәнлеге имиджын күтәрү |
| 11. | Һөнәри бәйрәмнәр (Сәүдә хезмәткәрләре көне, Машина төзүчеләр көне, Икътисадчылар | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү | 2024-2027 еллар | Бүләкләнүчеләр саны, кеше | 20 | 20 | 20 | 20 | 20 | 40,0 | 40,0 | 40,0 | 40,0 | Эшмәкәрлек эшчәнлеге имиджын күтәрү |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | көне) кысаларында, иң яхшы хезмәткәрләрне хөрмәтләү | идарәсе, Башкарма комитетның оештыру бүлеге | | | | | | | | | | | |
| 12. | Төзүчеләр көне, тармакның иң яхшы хезмәткәрләрен хөрмәтләү | Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе, Башкарма комитетның оештыру бүлеге | 2024-2027 еллар | Бүләкләнүчеләр саны, кеше | 10 | 10 | 10 | 10 | 10 | 17,3 | 17,3 | 17,3 | 17,3 | Эшмәкәрлек эшчәнлеге имиджын күтәрү |
| 13. | Автомобиль транспорты хезмәткәрләре көне, тармакның иң яхшы хезмәткәрләрен хөрмәтләү | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе, Башкарма комитетның оештыру бүлеге | 2024-2027 еллар | Бүләкләнүчеләр саны, кеше | 10 | 10 | 10 | 10 | 10 | 20,0 | 20,0 | 20,0 | 20,0 | |
| 5 бурыч. Кооперация элемтәләрен үстерү | | | | | | | | | | | | | |
| 14. | Ярминкәләр, җирле товар җитештерүчеләрнең продукцияләрен һәм хезмәтләрен алга җибәрү буенча чаралар үткәрү | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе | 2024-2027 еллар | Үткәрелгән ярминкәләр, чаралар саны, берәмлек | 130 | 135 | 140 | 145 | 150 | - | - | - | - | Продукция сатуда ярдәм күрсәтү, җирле производство продукциясен сату күләмен арттыру |
| 15. | Презентацияле очрашулар, чаралар, күчмә бизнес-миссияләр оештыру | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе, Башкарма комитетның алгарышлы үсеш территориясен | 2024-2027 еллар | Очрашулар саны, берәмлек | 8 | 11 | 12 | 12 | 12 | - | - | - | - | Продукция сату базарларын киңәйтү. Җитештерү буенча яңа кооперация элемтәләрен оештыру |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | үстерү бүлеге | | | | | | | | | | | |
| 16. | Шәһәр Советының йомгаклау утырышы кысаларында күргәзмә үткәрү | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе | 2024-2027 еллар | Күргәзмәдә катнашучылар саны, берәмлек | 40 | 45 | 45 | 45 | 45 | 300,0 | 300,0 | 300,0 | 300,0 | Яңа кооперация элемтәләрен үстерү өчен предприятие элемтәләрен киңәйтү |
| 6. Басма продукция сату буенча стационар булмаган сәүдә объектлары белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен күтәрү. | | | | | | | | | | | | | |
| 17. | Басма продукция сату буенча стационар булмаган сәүдә объектлары санын арттыру | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе | 2024-2027 еллар | Басма продукция сату буенча стационар булмаган сәүдә объектларының саны, берәмлек | 0 | 3 | 4 | 5 | 6 | - | - | - | - | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә фактта урнаштырылган, басма продукция буенча махсуслашкан стационар булмаган сәүдә объектлары санын арттыру |
| 18. | Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга бәйле проблемалы мәсьәләләрне хәл итү өчен, басма продукция сату эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган хуҗалык итүче субъектлар белән үзара эшчәнлек | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе | 2024-2027 еллар | Эшмәкәрләр белән очрашулар саны, берәмлек | 2 | 3 | 3 | 2 | 3 | - | - | - | - | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә фактта урнаштырылган, басма продукция буенча махсуслашкан стационар булмаган сәүдә объектлары санын арттыру |
| Программа буенча барлыгы: | | | | | | | | | | 578,3 | 578,3 | 578,3 | 578,3 | |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева